**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Зур Кырлаңгы авылында гражданнар җыены карары**

12 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Зур Кырлаңгы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Зур Кырлаңгы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- Зур Кырлаңгы авылындагы торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, балалар мәйданчыгын төзекләндерү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Зур Кырлаңгы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы __________ Р.Н.Шәрәфетдинов

Гражданнар җыены секретаре __________ А.И.Гәляутдинова